ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯҢГУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«19» июнь 2025 ел

**КАРАР**
№ 37

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану турында

Гамәлдәге законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Яңгул авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге башкарма комитетының 15.05.2011 ел, №28 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гражданнар һәм юридик затлар мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында («җирлекләр бүлегендә») урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru)

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гыйльфанов